Кунакка чакыру

Сорауларны укыйбыз,җавап бирәбез.

“А”

-Төлке белән Торна ничек яшиләр?

-Төлке кемне кунакка чакыра?

-Ул нәрсә пешерә?

-Ботканы кем ашый?

“Б”

-Торна кемне кунакка чакыра?

-Ул нәрсә пешерә?

-Торна нәрсә ди?

-Ни өчен Төлке белән Торнаның дуслыгы бетә?

КУНАКТА ҮЗЕҢНЕ ТОТУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

- Үзеңне тыныч тотарга кирәк. Кычкырып сөйләшергә ярамый.
- Матур итеп,чиста-пөхтә киенеп килергә кирәк. Ямьсез киенеп кунакка бармыйлар.
- Хуҗалар белән әдәпле итеп исәнләшәләр,матур итеп күчтәнәчләрне, бүләкләрне тапшыралар.
- Өстәл артында алдыңа куелган тәлинкәдән генә ашыйлар. Кеше алдына үрелеп утырмыйлар.
- Берәр әйбер кирәк булса, зинһар өчен алып бирегез дип сорарга кирәк.
- Өстәл артыннан кузгалганда рәхмәт әйтә белергә кирәк.
- Өйгә кайтканда хуҗаларга рәхмәт әйтеп, саубуллашып кайтып китәргә кирәк.

Тылсымлы сүзләр

- Исәнмесез.
- Хәерле көн.
- Рәхим итегез.
- Зинһар өчен.
- Рәхмәт.
- Таныш булыгыз.
- Гафу итегез.
- Кичерегез.
- Керергә мөмкинме?
- Туган көнең белән.
- Ашыгыз тәмле булсын.
- Безгә кунакка килегез.
- Сау булыгыз.
- Хәерле юл.

МӘКАЛЬЛӘР

- Кунак ашы - кара каршы.
- Кунак булсаң - тыйнак бул.
- Кунакка барсаң, кунак көт.
- Яхшы ашка - кыстау кирәкми.

Татар халык ашлары

3-2-1.

- 3 Ошады:
- 2 Ошамады:
- 1 Аңламадым:

Өй эше

- ”Кунакта” дигән темага диалог язып килергә.